**WorldSkills Kazan 2019**

WorldSkills стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты Россиядә беренче тапкыр уздырыла. Конкурсантлар төрле өлкәләрне колачлаган 56 компетенция буенча ярышачаклар – агач эшеннән алып мобиль робот техникасына, флористикадан алып авиация техникасына хезмәт күрсәтүгә кадәр.

WorldSkills Kazan 2019 чемпионаты һәм аның кысаларында үткәрелүче Эшлекле программа яшьләрне эшче һөнәрләрне үзләштерергә мотивация бирүгә юнәлдерелгән. WorldSkills International һәм катнашучы илләрдәге WorldSkills оешмалары әлеге һөнәрләрне үстерүгә зур өлеш кертә.

**ТӨП ФАКТЛАР**

- WorldSkills – 82 ил һәм төбәкне берләштерүче глобаль хәрәкәт. Аның максаты – һөнәри белем сыйфатын һәм эшче һөнәрләр абруен күтәрү.
- WorldSkills стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты – иң абруйлы халыкара эшче һөнәрләр чемпионаты.
- 1950 елдан башлап, чемпионат һәр ике ел саен төрле илләрдә үткәрелә. 2019 елда 45 нче чемпионатны Казан шәһәре (Россия) кабул итә.
- WorldSkills Kazan 2019 чемпионаты хәрәкәт тарихында иң зурысы булыр дип көтелә. Ул 2019 елның 22-27 август көннәрендә узачак (23-26 август көннәрен дә кертеп, “Казан Экспо” халыкара күргәзмәләр үзәгендә 4 ярыш көне булачак). Ачылу һәм ябылу тантаналары 22 һәм 27 август көннәренә планлаштырылган, тантаналар үткәрү урыны – “Казан Арена” стадионы.
- WorldSkills хәрәкәтендә катнашучы 63 ил һәм төбәктән конкурсантлар көтелә.
- Ярышлар түбәндәге алты өлкәгә керүче 56 компетенция буенча ярышачаклар, болар – “Төзелеш һәм төзелеш технологияләре”, “Иҗат һәм дизайн”, “Информацион һәм коммуникацион технологияләр”, “Җитештерү һәм инженерлык технологияләре”, “Хезмәт күрсәтү сферасы”, “Транспорт һәм логистика”.
- WorldSkills Kazan 2019 чемпионатында 1300 артык конкурсант ярышачак, аларның нәтиҗәләрен шуның кадәр эксперт бәяләячәк. Чарага бар дөньядан 250 меңгә якын тамашачы килер дип көтелә.
- Оештыру комитеты 14 000 волонтер заявкасы алган, шуларның өч мең биш йөзе WorldSkills Kazan 2019 чемпионатында ярдәм күрсәтү өчен сайланып алынган.
- Даими һәм вакытлыча корылмаларны да кертеп, “Казан Экспо” халыкара күргәзмәләр үзәгендә чемпионат өчен махсус рәвештә 76 мең квадрат метрлы мәйдан төзелгән – бу Мәскәүнең Кызыл мәйданы белән чагыштырырлык.

**WorldSkills Kazan 2019 – кызыклы фактлар һәм саннар**

- WorldSkills стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты алдыннан беренче тапкыр аның флагының эстафетасы узды. 2018 елның февралендә WorldSkills рәсми флагы “Союз” корабле бортында халыкара космик станциягә очты, аның сәяхәтенең иң югары тизлеге 28 000 км/сәг, ә биеклеге 408 км тәшкил итте. Соңрак ул үзенең юлын элегрәк чемпионат кабул иткән илләр буенча дәвам итте.
- WorldSkills Kazan 2019 чемпионаты конкурсантлары һәм экспертлары бу вакыйга өчен махсус әзерләнгән14 мең кеше сыйдырышлы WorldSkills Авылында яшәячәк, бу дөньядагы иң зур киң фюзеляжлы 26 Airbus 380 реактив очкычы сыйдырырлык пассаҗирлар санына тиң.
- WorldSkills дөнья чемпионаты үзгәреп торучы дөнья белән бер дулкында булыр өчен һәрдаим үсештә булырга тырыша. 2019 елда конкурсантлар беренче тапкыр “Су технологияләре” һәм “Кунакханә белән идарә итү” компетенцияләрендә ярышачаклар, узган чемпионатта дебют ясаган радио һәм ТВ ремонтлау буенча компетенция төшерелеп калдырылган. Кайбер компетенцияләр, мәсәлән, сантехника һәм җылыту системалары, кирпеч салу чемпионат оештырылганнан бирле бар.
- Чемпионат компетенцияләре бер-берсеннән нык аерылалар, әмма кирпеч салумы ул, яки икмәк пешерүме, барлык 56 компетенциядә дә кирәк предметлар бар: мәсәлән, ут сүндергечләр, ручкалар, һәм, әлбәттә, кофе машиналары.
- Бер типтагы иң зур күләмле материал “Матбугатта басма технологияләр” компетенциясендә кирәк булачак – 150 000 кәгазь бите. “Сантехника һәм җылыту системалары” компетенциясендә ярышучы конкурсантлар өчен 30 400 шөреп кирәк булачак. Ресторан хезмәте белгечләре кулланышында 1000 коктейль таякчыгы булачак.
- Моннан тыш, WorldSkills Kazan 2019 чемпионатын оештыру өчен махсус 24 800 кирпеч, 1944 стакан, 450 пешекче баш киеме, 24 838 чын чәчәк, 22 дрон, 2 вертолет, шулай ук 4 (!) Эверест тавы биеклегенә тиң булган 35 000 метрлы электр кабеле юнәтелгән.
- “Авиация техникасына хезмәт күрсәтү” компетенциясе конкурсантлары өчен 65 төр һәм зурлыктагы шөреп боргычлары әзерләнгән. Архитектор-ташчыларга 5 төрле таш кирәк булачак. Казанда узучы чемпионат өчен 56 компетенция буенча җайланмаларга барлыгы 21 412 заявка бирелгән.
- Космик системалар инженериясе – Казанда узучы чемпионатның Future Skills проекты компетенцияләренең берсе. Конкурсантларга биремнәр үтәр өчен кирәкле 155 җиһаз арасында Җир һәм Кояш моделе, 3D-принтер, лазер кисү өчен станоклар, цифрлы осциллограф, шулай ук 3 степлер бар.

## **WorldSkills International Халыкара оешмасы**

2020 елда WorldSkills оешмасының бөтен дөнья яшьләре арасында һөнәри осталык буенча чемпионат уздыра башлавына 70 ел тула. Осталык күнекмәләрен камилләштерү буенча дөнья үзәге буларак, WorldSkills яшьләрне, мөгаллимнәрне, хөкүмәт һәм профильле тармакларны берләштерә.

WorldSkills стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты - WorldSkills оешмасының иң мөһим вакыйгасы. Чемпионатта дөньяның бар почмагыннан килгән яшь профессионаллар катнаша. Конкурсантлардан тыш, чарага министрлык делегацияләре, югары дәрәҗәдәге дәүләт хезмәткәрләре, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре, һәм шулай ук тармак партнерлары җәлеп ителгән: алар өчен Эшлекле программа һәм элемтәләрне ныгыту буенча өстәмә чаралар уздырылачак.

### ТӨП ФАКТЛАР

- WorldSkills халыкара оешмасына 1950 елда Испаниядә нигез салына, һәм ул хәзерге вакытта икътисади үсеше төрле дәрәҗәдә булган 82 ил һәм төбәкне колачлый. Дөнья халкының өчтән икедән артык өлеше WorldSkills хәрәкәтендә катнашучы ил һәм төбәк территорияләрендә яши.
- WorldSkills стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты хәрәкәтнең иң мөһим вакыйгасы һәм эшче белгечлекләр арасында иң зур халыкара ярыш булып тора. Әгәр 1950 елда ярышларда Португалиядән һәм Испаниядән нибары 12 конкурсант катнашкан булса, 2019 елда Чемпионатта катнашуларын WorldSkills хәрәкәтенә кушылган 63 ил һәм төбәктән 1300 артык конкурсант раслады.
- WorldSkills чемпионаты һәр ике ел саен уздырыла һәм бөтен дөнья конкурсантларына төрле белгечлекләр буенча үзләренең һөнәри дәрәҗәләрен күрсәтергә мөмкинлек бирә. Ярышларда WorldSkills хәрәкәтенә кушылган илләр һәм төбәкләрнең һөнәри осталык буенча җирле, төбәк һәм милли чемпионатлары җиңүчеләре катнаша.
- WorldSkills Kazan 2019 чемпионаты – сан ягыннан WorldSkills халыкара хәрәкәтенең 45 нче чемпионаты. Чемпионат үз тарихында беренче тапкыр Россия Федерациясе территориясендә – Татарстан Республикасында уза. 2021 елда чемпионат беренче тапкыр Кытай территориясендә – Шанхайда узачак.
- Чемпионат ахырында конкурсантларга алтын, көмеш һәм бронза медальләр тапшырыла. Үз компетенцияләрендә уртача баллдан югарырак нәтиҗәгә ирешкән конкурсантлар “Югары осталык өчен” медале белән бүләкләнә.
- WorldSkills чемпионатының иң югары баллга ия булучы конкурсантына WorldSkills хәрәкәтенә нигез салган Альберт Видал исемендәге премия тапшырыла.
- Чемпионат кысаларында икътисад, хөкүмәт һәм белем бирү учреждениеләре тәҗрибә белән уртаклаша, һәм кадрлар әзерләү, профильле белем бирүдә иң әһәмиятле һәм актуаль сораулар хакында фикер алыша.

**<u>Чемпионатның Эшлекле программасы. Тормышны үзгәртүче күнекмәләр</u>**

Чемпионатның Эшлекле программасы бар дөньяның мәгариф, идарә, эшлекле һәм сәнәгый даирәләренең йогынтылы вәкилләрен тәҗрибә алмашу, һәм шулай ук эшче һөнәрләргә укыту өлкәсен кадрлар белән тәэмин итү, киләчәк һөнәрләр, квалификацияне күтәрү һәм һөнәри үсеш системаларында дөнья трендларын һәм мәсьәләләрен өйрәнү өчен җыя.

Эшлекле программа дөньяда эшче белгечлекләр буенча иң эре ярышлар – һөнәри осталык буенча WorldSkills чемпионаты кысаларында узачак. Хөкүмәт вәкилләре, экспертлар һәм төрле илләрдән җыелган идея белән рухландыручылар әлеге һөнәрләрнең киләчәген, аларның ни рәвешле икътисадка һәм җәмгыятькә күбрәк файда китерә алуын тикшерәчәкләр һәм шул хакта фикер алышачаклар.

**ТӨП ФАКТЛАР**

- Быелгы Эшлекле программа “Skills for Change: Building Blocks for Impact” (“Тормышны үзгәртүче күнекмәләр”) исеме астында уздырыла. Катнашучылар җәмгыятьтә очраучы проблемалар һәм глобаль тенденцияләрне, һәм шулай ук эшче һөнәрләрнең аларны хәл итүдә ничек ярдәм итә алачакларын өйрәнәчәкләр.

- Чемпионатның Эшлекле программасының халыкара трегы 23 һәм 24 август көннәрендә “Казан Экспо” халыкара күргәзмәләр үзәгендә узачак. Чараның өченче көнендә, 25 августа, Россия чынбарлыгына карата халыкара тәҗрибә каралачак милли трек узачак.

- Эшлекле программа белән стратегик җитәкчелекне WorldSkills эшлекле программа коалициясе (WorldSkills Conference Coalition) тәэмин итә, алар арасына ЮНЕСКО, Европа комиссиясе, Африка берлеге һәм Халыкара хезмәт оешмасы кебек әйдәп баручы халыкара оешма вәкилләре керә.

- Эшлекле программа дискуссиясе спикерлары һәм катнашучылары арасында кадрлар әзерләү өлкәсендә лидер оешмалар, әйдәп баручы корпорацияләр, һәм шулай ук эшче һөнәрләр дөньясы аркылы үз-үзләре һәм бөтен дөнья өчен искиткеч мөмкинлекләр ачучы яшьләрнең актив вәкилләре бар.

- Эшлекле программа чаралары өч трекка бүленгән: икътисад, җәмгыять үсеше һәм шулай ук тотрыклы экосистема булдыру өчен кадрлар.

- Чемпионатның Эшлекле программасы кысаларында Министрлар саммиты узачак, бирегә утыз биштән артык илдән килгән министрлар һәм җитәкчеләр кадрлар тәэмин ителеше өлкәсендәге соңгы яңалыклар хакында фикер алышачаклар.